| | | |
|---|---|---|
| **ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31 гыйнвар 2014 ел № 7-1/т

Казан шәһәре

***Казан шәһәрендә җәмәгать транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында***

“Бәяләрне (тарифлар) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында” 7 март, 1995 ел, №239 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, 15 июнь, 2010 ел, №468 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карар бирә:

1. Бу карарга кушымта нигезендә, Казан шәһәре җәмәгать транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләргә.
2. “Казан шәһәрендә җәмәгать транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында” 08 февраль, 2013 ел, № 7-3/т Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карарының 1нче пункты үз көчен югалткан дип танырга.
3. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча
дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
карарына кушымта
31 гыйнвар 2014 ел. № 7-1/т

## Казан шәһәрендә җәмәгать транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлары

| Транспорт төре | Бер тапкыр транспортта бару һәм 1 урын багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлары (сум) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | транспорт салонында билет алган чакта (метрополитен кассасында жетон алган чакта) | озак вакыт куллану билеты белән бару өчен түләм | | |
| | | 1 бару[1] | 10 тапкыр бару[2] | 50 тапкыр бару[2] |
| Трамвай | 20 | 18 | 18 | 10 |
| Троллейбус | 20 | 18 | 18 | 12 |
| Метро | 20 | 18 | 18 | 12 |
| Автобус | 20 | 18 | 18 | 15 |

<1> билгеле бер бәягә барырга мөмкинлек биргән, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм;

<2> билгеле бер бәягә ничә тапкыр барырга мөмкинлек биргән, озак вакыт куллану билеты белән шәһәр транспортында бару өчен түләм.

Искәрмә. Багаж алып бару өчен аерым транспортта бару бәясенә өстәп түләнелә.

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге